**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3726**
**19.07.2019**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен грантлар алуга конкурс үткәрү турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2014 елның 8 декабрендәге 7614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен грантлар алуга конкурс үткәрү турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2014 елның 8 декабрендәге 7614 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 8 августындагы 4069 нчы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен грантлар алуга конкурс үткәрү турында нигезнамәнең (алга таба – нигезнамә) 3 пунктында «25 июньнән 10 июльгә кадәр» сүзләрен «25 июньнән 23 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2) нигезнамәнең 7 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) претендентның бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре «Казан дәүләт медицина университеты» ЮББ ФДБМУ тарафыннан ел саен раслана торган керү сынауларын уңышлы узуны раслаучы минималь баллар санынннан ким булмаска тиеш»;

3) нигезнамәнең 17 пунктында «25 июньнән 10 июльгә кадәр» сүзләрен «25 июньнән 23 июльгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

4) Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен грантлар алуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 19 июлендәге
3726 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен
квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен
грантлар алуга конкурс үткәрү буенча
конкурс комиссиясе составы

1. Абдуллин Ринат Әзһәр улы – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе;
2. Хәлимов Рамил Мәрван улы – комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;
3. Хөсәенова Альбина Шамил кызы – комиссиянең җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге консультанты (килешенү буенча);

комиссия әгъзалары:

4. Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча);
5. Валгушева Гөлнара Илдус кызы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенең сәламәтлек саклау ресурслары белән оештыру-икътисадый идарә итү бүлеге башлыгы (килешенү буенча);
6. Камалетдинова Ләлә Әнвәр кызы – Шәһәр Советының гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе (килешенү буенча);
7. Миңнеханова Лилия Илсур кызы – Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең һөнәри белем бирүне үстерү бүлекчәсе мөдире;
8. Мөстәкыймова Әнисә Әнис кызы – «Казан дәүләт медицина университеты» ЮББ ФДБМУ Яр Чаллы шәһәрендәге вәкиллеге директоры (килешенү буенча);
9. Ревякина Анжелика Константиновна – «Медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» ДБССУ баш белгече (килешенү буенча);
10. Фатыйхов Нияз Шамил улы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешенү буенча);
11. Шәйхетдинова Альбина Марат кызы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары, халыкка дәвалау һәм профилактика ярдәме бүлеге башлыгы (килешенү буенча).

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова